Саранск кешесе интим хезмәт алырга теләп, мошенникларга сигез тапкыр акча күчергән.

Түләүле интим хезмәтләр теләге Саранск кешесен мошенникларга китергән. Тобәк эчке эшләр министрлыгы хәбәр иткәнчә, 55 яшьлек предприятиеләрнен берсенен бүлек житәкчесе акчаны сигез тапкыр билгесезләргә күчергән, һәм аны кредит алырга сорагач кына, эшнен чиста түгеллеген анлаган. Гомумән алганда, ул билгесезләргә 163 мен сум күчергән.

Барлык күчерүләрне тонлә анын йортыннан берничә кварталда урнашкан банкомат аша башкарган.

Хәзер мошенниклык факты буенча жинаять эше кузгатылган.

Тагы бер алдану. Игезәк сайтлардан сакланыгыз! Россия Эчке эшләр министрлыгынын Рузаевка районы буенча дежур частенә жирле яшәүче, башлангыч сыйныфлар укытучысы үзенә карата кылынган мошенниклык турында гариза белән морәжәгать иткән. Зыян күләме 380 мен сум тәшкил иткән.

Зыян күрүче сөйләгәнчә, ул гаиләсе белән күптәнге хыялын тормышка ашырырга һәм ой очен сауна сатып алырга карар кылган. Интернетта алар «Кедр-бочка» исемле сайттан кызыклы тәкъдим тапканнар. Сатып алу табыш вәгъдә итә: арзан бәя, акция һәм тиз китерү. Бернәрсәдән дә шикләнмичә, ха-тын-кыз компаниянен «менеджеры» белән элемтәгә кергән. Ул аны производствога заказ жибәрү очен алдан түләү кирәклегенә ышандырган. Ышанучан сатып алучы ботен сумманы - 380 мен сумны - күрсәтелгән банк счетына күчергән. Ләкин китерү вакыты житкәч, мичкә мунчасы килеп житмәгән. Сонрак ачыкланганча, гаилә чынбарлыкта булган фирманын дизайнын һәм контентын күчереп, ялган игезәк сайт булдырган мошенникларнын корбаны булган.

Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы искә тошерә: сатып алу алдыннан компания турындагы фикерләрне анын үз сайтында гына түгел, ә бәйсез мәйданчыкларда да эзләгез. Артык түбән бәяләргә ышанмагыз. Кызыктыргыч акция-игътибар жәлеп итүнен һәм уяулыкны йоклатунын еш ысулы. Алдан түләүнен бер олешен таләп итегез. Намуслы сатучылар, кагыйдә буларак, товар алганда түләүгә ризалаша яки алдан түләүне 10-30% күләмендә ала, тик 100% түгел. Сайтны игътибар белән ойрәнегез. Текстлардагы хаталар, компания турында аз мәгълүмат, юридик адрес һәм телефоннар булмау - хәвефле сигналлар. Адрес юлына игътибар итегез. Ышанычлы сайтлар саклаулы тоташуны (https:// һәм йозак билгесен) кулланалар.

Исегездә тотыгыз: сезнен уяулыгыгыз - аферистларга каршы топ сак. Алдаунын беренче билгеләре булганда ук кичекмәстән полициягә морәжәгать итегез.